Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә Советы

# КАРАРЫ

25 ноябрь 2020 ел №8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 156 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең территориясендә җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә

Түбән Мактама бистә Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 156 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең территориясендә җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац белән тулыландырырга:

«гражданнар күмү белән шөгыльләнүче оешмалар, учреждениеләргә карата җир кишәрлекләре»;

1.2. бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистә Башлыгына йөкләргә.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов